Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 30 (43)

1 ноябрь 2012 ел

## • Универ хәлләре

29 октябрь көнне ректор **ИЛШАТ ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ РЕКТОРАТ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Беренче булып, Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин КФУдагы Үсеш программасының барышы белән таныштырды. Аннан соң «Журналистика һәм социология факультеты, КФУның гомуми корпоратив мәгълүмати сәясәтендә яңа оештыру алымнары» темасы белән Медиа-үзәк директоры Илдар Кәримов чыгыш ясады. Ул университетның «UNIVER TV» студентлар телевидениесе эшчәнлеге турында мәгълүмат бирде. Инновацион эшчәнлек буенча проректор Наил Кашапов 13-26 октябрь көннәрендә КФУ делегациясе составында инновацион үсеш идарәсе һәм кече инновацион предприятиеләр вәкилләре стажировкасы уңаеннан Heriot-Watt (Шотландия) университетына бару турында хисап бирде. Әлеге очрашу нигезендә Heriot-Watt университеты белән үзара килешү турында меморандумга кул куелган.

• • • •

29 октябрь көнне ТР Дәүләт Советы Рәисе **ФӘРИТ МӨХӘММӘТШИН** республика парламентына сайланган депутатларга, ректорыбыз **ИЛШАТ ГАФУРОВ** һәм **МАРАТ ЗАРИПОВКА** таныклык һәм күкрәк билгесен тапшырды.

• • • •

Шул ук көнне Актлар залында Казан университеты ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** яшь хезмәткәрләр: **ИНСТИТУТ ҺӘМ ФАКУЛЬТЕТЛАРНЫҢ АССИСТЕНТЛАРЫ, МӨГАЛЛИМНӘР ҺӘМ ӨЛКӘН УКЫТУЧЫЛАРЫ БЕЛӘН ОЧРАШУ УЗДЫРДЫ**. Җыелуның сәбәбе: хезмәт хакы турында сөйләшү. И.Гафуров алда санап үтелгән категория хезмәткәрләренә (30 яшькә кадәр) 3 ел дәвамында хезмәт хакларына өстәмә акча түләргә дигән тәкъдим белән чыгыш ясады.

• • • •

29 октябрьдә Татарстан Республикасы Конституциясенә 20 ел тулу уңаеннан **КФУНЫҢ ЮРИДИК ФАКУЛЬТЕТ СТУДЕНТЛАРЫ ТРНЫҢ КОНСТИТУЦИОН СУДЫНА БАРЫП КАЙТТЫЛАР**. Анда эшләүчеләр яшь белгечләргә республика Конституциясенең тарихы турында сөйләде, шулай ук конституцион судья буларак шәхси тәҗрибәләре белән дә уртаклашты. Соңыннан студентлар үзләрен кызыксындырган теоретик һәм гамәли сорауларына җавап алды.

• • • •

2012 елның ноябреннән башлап **КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ БАЗАСЫНДА КОНФУЦИЙ ИНСТИТУТЫ КЫТАЙ ТЕЛЕН ТЕСТЛАШТЫРУ БУЕНЧА ХАЛЫКАРА ҮЗӘККӘ ӘЙЛӘНДЕ**. Монда төрле дәрәҗәдәге HSK (Hanyu Shuipin Kaoshi) имтиханын тапшырырга мөмкин. Быел тапшырырга теләүчеләр www.chinesetesting.cn сайтында 4 ноябрьгә кадәр регистрация үтәргә тиеш. Беренче имтихан 2012 елның 2 декабрендә узачак. Тулырак мәгълүматны 292-82-11, 8987-235-36-77 (Әлфия Рафисовна) телефонына шалтыратып яисә Пушкин ур. 1/55, 3 кат, 321 һәм 305 бүлмәләрдән белешеп була.

• • • •

31 октябрь көнне Казан федераль университетында **«PROQUEST МӘГЪЛҮМАТЛАР БАЗАСЫНДАГЫ ФӘННИ МӘГЪЛҮМАТ: ЗАМАНЧА ФОРМАЛАР ҺӘМ ЯҢА ТЕХНОЛОГИЯЛӘР» ДИП ИСЕМЛӘНГӘН СЕМИНАР УЗДЫ**. «Конэк» Ябык Акционерлык Җәмгыяте язылу агентлыгының электрон ресурслар бүлеге җитәкчесе яңа ProQuest платформасы турында мәгълүмат бирде һәм аның эшләү алгоритмы белән таныштырды. Хәзерге вакытта Казан федераль университетында ProQuest SciTech Collection мәгълүматлар базасында тестлы файдалану мөмкинлеге булдырылган. Тестлаштыру 2012 елның 21 ноябренә кадәр дәвам итәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




# Казанда ислам форумы

29-31 октябрь көннәрендә Казанда «Ислам күп мәдәниятле дөньяда» II халыкара форум узды. 29 октябрьдә УНИКСның Кече залында Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының төбәкләрне һәм исламны өйрәнү кафедрасы оештырган әлеге чараның тантаналы ачылышы үтте.

Форумда катнашырга Бельгия, Бөекбритания, Нидерланд, АКШ, Төркия, Япония, Украина, Азәрбайҗан, Польша, Әрмәнстан, Германия һәм Россиянең Мәскәү, Санкт-Петербург, Махачкала, Уфа, Чиләбе, Оренбург кебек шәһәрләреннән ислам белгечләре килде.

Чараны КФУның Тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов ачып җибәрде: «Шәрык халкының дөньяга карашын, менталитетын өйрәнү илләр арасында яхшы мөнәсәбәт урнаштыру өчен бик әһәмиятле», – дип билгеләп үтте.

Проректор кунакларны Казан (Идел буе) федераль университеты эшчәнлеге, шулай ук уку йортыбызда исламны өйрәнү өлкәсендәге тикшеренүләр белән таныштырды. Линар Латыйпов сүзләренчә, мондый тикшеренүләр Филология һәм сәнгать институтында, Тарих институтында, Идарә һәм территориаль үсеш институтында, юридик факультетта үткәрелә. Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының төбәкләрне һәм исламны өйрәнү кафедрасы - бу тикшеренүләрнең үзәге.

Форумның актуальлеген Россия Ислам университетының ректоры Рафыйк Мөхәммәтшин да билгеләп үтте. «Күрүебезчә, ислам безнең иҗтимагый-сәяси, рухи тормышыбызга кереп бара. Ни кызганыч, илебездәге ислам җәмгыятендәге процессларын анализлап өлгермибез. Шуңа күрә Россия җәмгыятенә фәнни берләшмәләр кирәк. Галимнәр безгә бу процессларны яхшырак аңларга ярдәм итәр», – ди Рафыйк Мөхәммәтшин.

Өч көн барган форумда галимнәр Россиядәге һәм дөньядагы исламның актуаль проблемалары, мөселман хәрәкәтләренең үсеше кебек мәсьәләләр хакында фикер алышты. Идел-Урал төбәгендә ислам көнкүрешенә аерым игътибар бирелде.

Шулай ук галимнәр «ислам белгече» термины турында дискуссия корды.

Төбәкләрне һәм исламны өйрәнү кафедрасы мөдире, профессор Ренат Беккин: «Без мондый форумны икенче тапкыр үткәрәбез. Былтыргы тәҗрибә күрсәткәнчә, Казан һәм Казан университеты - ислам белгечләренең очрашуы өчен менә дигән урын. Бу чара белгечләргә күп кенә мәсьәләләрне уртага салып сөйләшү, дөньядагы ислам тикшеренүләренең үсеш юнәлешләрен белер өчен уникаль мөмкинлек».

## • Бездә кунак бар

# Галим булсаң, галәм - синеке!

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Филология һәм сәнгать институтының роман-герман филологиясе бүлегендә зур кунак – Чехиянең Көньяк Богемия университеты профессоры Люси Бетакова. Аның Казан федераль университетына килүенең сәбәбе дә бик үзенчәлекле.



Рамил Газизов фотосы

Профессор «Инглиз теле укытучыларының компетенцияләрен формалаштыру һәм тел күнекмәләрен бәяләү» IV Темпус проекты кысаларында башкарылган эшнең сыйфатын тикшерү максатыннан мониторинг үткәрде. Проектның эшчәнлеге югары белем алу системасында зур әһәмияткә ия. Уку йортлары алдында торган конкурентлыкка сәләтле яшьләрне тәрбияләү максатын тормышка ашыруда әлеге проект зур роль уйный.

**Ахыры 2нче биттә.**

● Профессор киңәше

# Җәмил НИГЪМӘТОВ: «Укытучы күңел күзе белән күрсен!..»

**Рифат СӘЛАХ**

Педагогик белем бирү юнәлеше буенча укучы студентлар озакламый мәктәп-гимназияләргә практика узарга китәчәк. Кемнәрдер бу адымны түгә тапкыр ясый, ә кемнәрдер мондый чирканчык алырга өлгергәндер. Ничек кенә булмасын, без сезгә уңышлар телибез! Күренекле татар галиме, педагогика фәннәре докторы, профессор, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты, Россиянең атказанган фән эшлеклесе, Дуслык ордены кавалеры Җәмил Нигъмәтов биргән киңәшләр сезнең өчен бик файдалы булыр дип уйлыйбыз.

**– Ни өчен педагогика өлкәсен сайладыгыз?**

– Балачактан ук ике хыялым бар иде. Йә табиб-хирург, йә укытучы буласым килде. Балачакта укытучылы уйнаганда, барыбыз да укытучы булырга тырыша идек. Шуннан бирле укытучыларга зур хөрмәт белән карыйм.

**– Димәк, уен чынбарлыкка әйләнде?**

– Башта авиация училищесын тәмамладым. Бер дустым: «Әйдә, КАИга керик», – ди. «Юк, мин педагогика институтына математикага барам!», – дидем. «Укытучы нәрсә инде ул?» –ди. Инженер ничек яңгырый да, укытучы ничек яңгырый, имеш. «Юк, мин барыбер укытучы булам!» – дип үз сүземдә калдым. Шулай итеп теләгем белән балачактагы хыялымны тормышка ашырдым.

**– Сәләтсез бала булмый, диләр. Мәктәптә бөтен бала да яхшы укый аламы?**

– Укырга өйрәтеп була, әмма сәләт һәркемдә төрле. Укытучы үзенең фәнен генә түгел, ә физиологияне дә, психологияне дә белергә тиеш. Кайбер укытучылар: «Менә Иванов математикадан «бишле»гә укый, ә син Петров ник укый алмыйсың?» – ди. Андый сорау кую дөрес түгел. Ивановның юнәлеше төгәл фәннәргә, ә моның юнәлеше гуманитар фәннәргәдер. Бәлки бөтенләй спортсмен булыр ул. Уртача белемгә һәр кешене дә өйрәтеп була, ләкин бөтенесеннән дә отличник ясау дөрес түгел.

**– Тәҗрибәле педагог һәм педагогика фәне остазы буларак та әйтегез әле, укытучы булу өчен, кешегә табигый талант бирелергә тиешме?**

– Укытучылык сәләте, минемчә, ана сөте белән кергән булырга тиеш. Педагогик осталык һәм педагогик техника дигән төшенчәләр бар. Педагогик техникага өйрәтеп була, ә педагогик осталыкка, профессиональлеккә юк.



Укытучы ул һөнәр түгел, ә табигый сәләт. Шуңа күрә һәр кешедән дә яхшы укытучы әзерләп булмый. Татар халкында бер әйтем бар: күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге. Укытучы кеше балаларны күңел күзе белән күрергә, аларны аңларга, дөрес юнәлеш бирергә тиеш.

**– Мәктәптә хезмәт юлын башлап җибәргән яшь белгечләргә нинди киңәш бирер идегез?**

– Кайбер яшь укытучылар үзләренә укучыларны җәлеп итеп, эшләп китәләр, аптырап каласың. Кайвакыт егерме-утыз ел тәҗрибәсе булган укытучылар да үзләренә балаларны каратып, аларны буйсындыра, тәрбияли алмый. Беренчедән, яшь укытучы укучылар белән бергә дә булырга да, алдан барырга да тиеш. Ул беренче дәрескә кергәндә үк, андагы төрле карашлы атмосферага әзер булырга һәм аларга дөрес мөнәсәбәт белдерергә тиеш. Балалар алдында кызып китәргә, ачуланырга ярамый. Аны беренче кергәндә үк кочаклап алмаячаклар. Икенчедән, үз фәнен яхшы белгән, балаларны кызыксындарган укытучының дәресен генә ярататалар. Мавыктырып кына түгел, укытучы үзе дә мавыгып укытырга тиеш.

**– Сезнең шәхси укыту методыгыз бармы?**

– Методларга килгәндә, укытучы бөтен ысулларны дабелергә тиеш дигән сүз түгел. Үзе кайсы методлар белән уңышка ирешә, шуларын куллансын. Бер кешенең ысулы икенче кешегә ярамаска да мөмкин. Сыйныфта яхшы белгәннәр, начар белгәннәр була. Бөтен яхшы укучыларга теманы авырдан аңлаучыларга өйрәтергә кушам. Минем методика шундыйрак. Дәрестә мин генә укытучы түгел.

**– Сез җитәкче урыннарда эшләгән кеше: мәктәп директоры, югары уку йорты ректоры... Бу вазыйфаларны башкарганда педагогик белемегезне кулландыгызмы?**

– Көн саен кулланам дисәм дә ялгыш булмас. Математика мине мантыйкка өйрәтте. Кешене тыңлаганда, һәрвакыт мантыйгы барлыгын тикшереп, барсын да алгоритмга куеп эшли идем. Педагогика укытучыларга гына кирәкми. Бөтен тирә-ягыбызда аның белән һәрдаим очрашып торабыз.

**– Җылы әңгәмәгез өчен, рәхмәт, Җәмил абый.**

● Бездә кунак бар



Рамил Газизов фотосы

# Галим булсаң, галәм - синеке!

**Башы 1нче биттә.**

Проектта барысы 17 югары уку йорты катнаша. Шуларның 4е чит илдән: Бөекбританиядән ике уку йорты, Чехиянең Көньяк Богемия университеты, Германиянең Дрезден техник университеты. Россия уку йортлары арасында Казан федераль университетының катнашуы аеруча куанычлы хәл. Аны тормышка ашыруда Филология һәм сәнгать институты директоры, профессор Рәдиф Җамалетдинов, роман-герман филологиясе бүлеге мөдире, профессор Аида Садыйкова, профессор Марина Солнышкино катнаша. Проект Европадагы коллегалар белән бергә телне бәяли торган, академик кредитлаштыруның европа системасын һәм тестлаштыру буенча курслар булдыруны күз алдында тота. Нәтиҗәдә бу курслар барлык вузларда уку планына кертеләчәк. Киләчәктә аны мәктәп укытучылары да мәҗбүри рәвештә тыңларга тиеш булачак.

Европа Союзы тарафыннан зур финанс ярдәме (57 мең евро) алган проект оештыручыларының планнары зурдан. Контрастив лингвистика һәм лингводидактика кафедрасы профессоры Марина Солнышкина: «Хәзер безнең студентларыбыз чит илләрдә белем алырга омтыла. Әгәр без Европа системасының бер өлеше була алсак, биредәге курслар Европада укылачак, ә андагылар бездә тормышка ашырылачак», – диде. Партнерлык кысаларында институт укытучылары Бөекбританиядә һәм Германиядә стажировка үткән.

1 сентябрьдән роман-герман бүлегенең 4 курс студентлары әлеге юнәлеш буенча махсус электив дәресләр ала башлады, ул зачет белән төгәлләнәчәк. Бу студентларга бәхет икеләтә елмайды дияр идем. Аларның белем дәрәҗәсен тикшерергә Көньяк Богема университетыннан Люси ханым Бетакова килде. Ул студентларны дәрес барышында күзәтте, аралашты. Укытучылар өчен кызыклы лекцияләр, мастер-класслар уздырды. «Студентларның инглиз телендә иркен аралашуы, академик яктан яхшы әзерлекле булулары таң калдырды. Кабинетлар да заманча җиһазландырылган, китаплар һәркемгә җитә», – дип югары бәяләде эш тәртибен чит ил кунагы. Институт директоры Рәдиф Җамалетдинов белән очрашу барышында ике як киләчәктә дә хезмәттәшлекне дәвам итү турында килеште.

● Безнең канат

# Чаллы-Кытай арасы

**Динә МӨХТӘСИПОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә Яр Чаллы филиалында Кытай Халык Республикасына нигез салынганга 63 ел тулганны билгеләделәр. Гадәти булмаган чараны филиалдагы Кытай мәдәнияте үзәге оештырды.

Кичәгә кытай мәдәниятен яратучылар, аны өйрәнүчеләр җыелды. Чит телләр факультеты студентлары кунакларны романтик җыр белән сәламләде. Тамашачылар шулай ук Ромео һәм Джульеттаның матур мәхәббәт тарихын кытай телендә карау бәхетенә иреште.

Кытай мәдәнияте үзәге җитәкчесе Лариса Фролова кунакларны кытай телендә сәламләде. Хунань педагогика университеты (Кытай) укытучысы Ли Чжэнвэнь мондый истәлекле көнне Чаллы студентлары белән каршы алуга сөенүен белдерде. Кытай кунагы әйтүенчә, соңгы елларда аның туган теленә кызыксыну арткан. Болай дәвам итсә, ул дөньякүләмендә популярлыгы буенча инглиз теленнән соң икенче урын алып торачак.

Үзәк җитәкчесе чарага килгән кунакларга Кытайга бәйле белемнәрен тикшереп карарга тәкъдим итте. Символика, традиция, архитектурага бәйле сорауларга студентлар бик тулы җавап бирде. Әйтик, сез Кытай укучылары өчен иероглифларның минималь күләме 4 мең билге булырга тиешлеген белә идегезме? Кызык мәгълүмат. Оештыручы тарафыннан тәкъдим ителгән чираттагы биремне студентлар бик тиз башкарды. Безнең өчен шактый авыр тоелган кытайча сүзләрне алар бик җиңел генә укып чыкты.

Үзәктә студентлар телне өйрәнү белән генә чикләнми, алар кытайлыларның музыка, бию, әдәбият өлкәсен дә өйрәнә. Моңа студентлар башкарган бию чын дәлил булып тора. Студентлар теория белән генә чикләнми, белемнәрен гамәлдә дә бик актив кулланалар. 5 курс студенты Андрей Иванов Кытайда узган сәяхәте турында фотолар ярдәмендә сөйләп, тамашачыларда тагын да зур кызыксыну уятты.

Һәр илнең мәдәниятен, тарихын өйрәнгәндә, тагын бер әйбергә игътибар ителә. Ул – аш-су традицияләре. Чит ил кунагы Чжэнвэнь ханым милли ашлары турында бик матур итеп сөйләде. Куайцзу таякчыклары белән ничек ашарга кирәклегенә бәйле мастер-класс үткәрде. Безнең өчен бик чит тоелган «кашык»лар белән арахис яисә дөге ашау бер дә җиңел түгел.

Чара бөек Кытай турындагы «Чжунго» җыры белән төгәлләнде. Шуннан соң да кунаклар таралырга ашыкмады. Чираттагы очрашуга идеяләр, планнар белән уртаклашты. Кытай мәдәнияте үзәге һәр кешегә бүләк өләшә. Сез дә рәхим итегез!



● Чара

# Геометрия Коперникы

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
математика һәм механика
институты студенты

«Математика - акыл гимнастикасы»
*М.И.Калинин*

Әлеге сүзләр – күпләрне битараф калдырмаган, тормыш белән бергә атлаган, мәңге үлмәс, фәннәр патшасы бөеклегенә күтәрелгән математика турында.

Математика тарихына күз салсак, бөек грек математигы Евклид, Коперник заманыннан алып бүгенге көнгә кадәр әлеге фән бик катлаулы һәм озын юл үткән. Анри Пуанкаре, Карл Вейерштрасс, Карл Гаусс кебек бөек математикларның һәммәсе үз теориясен тәкъдим итеп, аны үзенчә дәлилләргә тырышкан. Математиканың аспектлары гел бер теориягә генә таянмаган, әлбәттә. Әлеге чор өчен лояль булмаган фикерләр актуаль проблемага әверелгән. Моны аңлатып та була: һәркем фәнгә үз өлешен кертергә, дөньякүләм танылырга теләгән.

Яңа, евклидча булмаган геометриягә нигез салучы, механика, астрономия, физика кебек өлкәләрдә үзенең алыштырмаслык хезмәтен калдырган бөек математик Николай Иванович Лобачевский шундыйларның берсе. Быел 1 декабрьдә аның тууына 220 ел була. Бу түгәрәк дата республикада гына түгел, Россиядә дә билгеләп үтеләчәк. Казан федераль университеты китапханәсе дә аның исемен йөртә. Николай Лобачевский 1827 – 1845 елларда университет ректоры булу белән беррәттән, университетның китапханәчесе вазифасын да башкара. Ул әлеге китапханәне матур һәм фәнни әдәбият, кирәкле материаллар белән тәэмин итә. Гомумән, университетыбыз Россиянең иң алдынгы уку йортларының берсенә әверелә. Ни кызганыч, бөтен гомерен фәнгә багышлап, егерме елга якын университет ректоры булып торганнан соң да, аңа кадәр дә, аннан соңгы елларда да хезмәтләре тиешенчә бәяләнми. Шунысы куандыра: бүгенге көндә күпкырлы шәхес, даһи галим, педагог, таланты һәм профессиональ җитәкче сыйфатларына ия булган Н.Лобачевский теориясенең уңышы һәм кулланылышы, һичшиксез, зур.

Шушы көннәрдә Бөек математикның 220 еллык юбилее уңаеннан, студентларны бу шәхес белән якынрак таныштыру максатыннан КФУның математика һәм механика институты тарафыннан җиденче конференция уздырылды. Бу зур датага багышлап, тантаналы чаралар, фәнни-гамәли конференцияләр үткәрү уңай күренеш, чөнки һәркем үз иленең бөек кешеләрен белергә, алар белән горурланырга тиеш. Лобачевский исемендәге китапханәдә үткәрелгән конференция кафедра җитәкчеләрен, математика һәм механика институты студентларын, 23 нче һәм 178 нче Казан мәктәпләренең югары сыйныф укучыларын җыйды. Конференция математика һәм механика институты директоры Владимир Чугунов һәм институт профессоры Лилиана Шакированың котлау сүзләре белән башланып китте. Ике сәгатькә сузылган чарада 5 курс студентлары тарафыннан Лобачевскийның тормыш юлы, күпкырлы эшчәнлеге турында эчтәлекле чыгыш әзерләнгән иде. Казан геометрия мәктәбенә нигез салучы геометр Петр Алексеевич Широковның биографиясе һәм эшчәнлеге турында да тулырак сөйләнелде. Аның оныгы Ольга Александровна Широкова – доцент, профессор конференциянең шәрәфле кунагы иде. Математика институты директоры Владимир Чугунов, кафедра җитәкчеләре әлеге конференциядә туган хис-кичерешләре белән уртаклашты. Чара ахырында иң актив студентлар һәм кунаклар бүләкләнде, Лобачевский турында фильм күрсәтелде. Һәр катнашучыга әле генә «пичтән чыккан» «Лобачевский һәм Казан математика мәктәбе» исемле китап тапшырылды. Шундый матур һәм эчтәлекле конференция оештырган өчен университет, математика һәм механика институты, китапханә администрациясенә, хезмәткәрләренә чиксез рәхмәт. Әлеге вакыйга һәркемнең күңелендә онытылмас хатирәләр калдырып, һәркем үзенә бик күп кызыклы мәгълүмат алгандыр дип ышанып калам. Чыннан да, Лобачевский кебек шундый шәхес булу өчен тырышлык, көн-төн эзләнүләр генә җитми, Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сәләткә дә ия булырга кирәктер. Кем белә, бәлки бездән дә Лобачевский, Коперник, Гаусс кебек бөек шәхесләр чыгар. Ләкин шунсы анык: мондый талант иясенең хезмәтләре бу илдә үз кулланучыларын табарга тиеш!

Лобачевскийның кыю идеяләре математика һәм университет тарихында тирән эз калдырды. «Геометрия Коперникы» бүгенге көндә һәммәбез өчен дә үрнәк, алыштыргысыз һәм бердәнбер. Мәңгегә шулай булсын!

● Бәйге



# Очраштыра да тел, берләштерә дә тел

*Лилия ЯКУПОВА,*
татар филологиясе бүлеге студенты

24 - 25 октябрь көннәрендә Удмурт дәүләт университетында Россия халыкларының телләре һәм әдәбиятлары буенча унберенче тапкыр олимпиада узды. Ел саен Ижау шәһәренә барып, яшьтәшләребез белән аралашып кайту күркәм традициягә әверелде.

Биргә уналты университеттан якут, бурят, алтай, мордва, мари, башкорт, удмурт, татар һәм башка милләт студентлары килгән иде. Очрашуда һәр команда презентация күрсәтте. Кимендә өч студенттан торган һәр төркем үз университеты, шәһәре белән таныштырды, милли биюләрен, җырларын, хәтта ризыкларын да тәкъдим итте. Конкурсантлар бер-берсенә уңышлар теләде.

Студентлар беренче көнне әдәбияттан, икенче көнне ана теле буенча биремнәрне үтәде. Әйтергә кирәк, биремнәр шактый катлаулы иде. Шулай да, конкурсантлар куркып калмады, киресенчә, җиңү теләге көчәйде генә. Әҗиңүчеләр - Удмуртия, Коми һәм Мордовия студентлары. Казан (Идел буе) федераль университеты студентлары Яппарова Гөлназ һәм Якупова Лилия аерым номинацияләрдә дипломга лаек булды.

Удмурт дәүләт университетының удмурт филологиясе факультетында яңа оешкан «Ватка» театр студиясе «Яратон, яратон» («Мәхәббәт, мәхәббәт») исемле спектакльләрен тәкъдим итте. Тамашачылар, төрле милләт студентлары булуларына да карамастан, бу спектакльне бик яратып карадылар. Артистлары да гади студентлар, әмма уйнауларына карап алай гына димәссең! Телләре аңлашылмаса да, йөрәктән чыккан хисләр үз юлын тапты.

Мондый очрашулар бик тансык безгә. Әлеге фикерне минем яшьтәшләрем дә хуплады. Азалия Хурамшина М.Акмулла исемендәге Башкортстан гуманитар педагогика университеты студенты, бу олимпиадада инде икенче тапкыр катнаша. «Россия халыкларының телләре һәм әдәбиятлары буенча олимпиадада катнашу төрле республика студентларына бер-берсенең мәдәниятен якынрак өйрәнергә, яңа дуслар табарга мөмкинлек бирә. Моннан тыш, бирелгән алган мәгълүматлар безгә һөнәри эшчәнлегебездә дә булышлык итәчәк һәм, ниһаять, бирелгән без көчебезне сыный алабыз», – дип белдерде. Таулы Алтай дәүләт университеты студенты Аруна Анчина да бу фикерләр белән килеште: «Бирелгән мин үзем өчен күп яңалыклар белдем, төрле халыкларның үзенчәлекле якларын күрдем», – дип өстәде.

Гомумән, удмурт филологиясе факультетында уздырылган бу ике көн бездә җылы тәэсирләр генә калдырды. Киләсе елда да очрашырга насыйп булсын иде дип таралыштык.

● Сәяхәттән кайткач

# Тарих эзеннән

**Альберт БОРҺАНОВ,**
Тарих институты профессоры

Октябрьдә миңа Кырым яклары, бу төбәкнең гүзәллеге белән хозурланып кайтырга насыйп булды. Әштән качып ял итәргә барган дип уйлый күрмәгез, фәнни командировка кысаларында каралган сәяхәт иде бу.

Чара «XIII-XV гасырларда Кырым төрки-мөселман мәдәнияте торгызу һәм тикшерү проблемалары» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференция кысаларында уздырылды. «Иске Кырым шәһәрендә «Үзбәк мәчет-мәдрәсәсе» милли-тарихи мирасны саклау» исемле «түгәрәк өстәл»дә катнашып, мин бик күп яңа мәгълүмат ишеттем. Алай гына да түгел, Кырым Автоном Республикасының (Украина) беренче шәһәрендә кунак булу бәхетенә ирештем.

Кырым-татар җәмгатьчелеге һәм Иске Кырым шәһәрендә яшәүчеләр инициативасы белән оештырылган конференциягә Украинаның Халык депутаты Ю.В.Левочкина да зур ярдәм күрсәтте.

Иске Кырымның Алтын Урда тарихи истәлекләрен музейлаштыру буенча беренче адымнар ясалган. «Түгәрәк өстәл» барышында әлеге һәм башка темаларга бәйле сөйләшү булды. Нәтиҗәдә, архитектура һәйкәлләрен саклау буенча актив эшчәнлек алып бара торган халыкара төркем булдырырга кирәк дигән фикергә килдек. Башлаган эш буенча уңышларга ирешү өчен, Азәрбайҗан, Казахстан, Төркия һәм Россия (Татарстан) фәнни-тикшеренү, реставрацион оешмалары белән хезмәттәшлекне ныгыту мөһим.

Без Иске Кырым шәһәрендәге тарихи мирас объектлары (Үзбәк мәчет-мәдрәсәсе, «Бейбарс» мәчете, археологик һәйкәлләр) белән таныштык. Мәдәни программа кысаларында Коктебль шәһәрендә урнашкан язучы һәм рәссам М.Волошин музее, Судака шәһәрендәге XIV гасырга караган Генуэз ныгытмасы объектлары буенча сәяхәт кылдык.

Бу җирләргә минем беренче баруым түгел. Шулай яңадан Бакчасарай һәйкәлләрен карап кайттым.



▲ Хаҗ-Гәрәй мавзолее калдыклары



▲ «Бейбарс» мәчете

▼ Археологик һәйкәлләр



2008-2012 елларда бирелгән урта гасырларга караган төрки-мөселман мирасын эзләү буенча зур масштаблы казу эшләре башкарылган иде. Алар барышында XV-XVIII гасырлардагы Зинҗер мәдрәсәсе, Хаҗ-Гәрәй мавзолее калдыклары (XV гасыр) өйрәнелде. XV-XVIII гасыр мунчасының (хамам) калдыклары табылды. Әлеге һәйкәлләр күптән түгел генә яңадан торгызылды.

Эшлекле сәяхәттән яңа мәгълүматлар тулы чемодан белән кайттым. Хәер, анда алган бөтен тәэсирләрне дә кәгазь битенә төшереп булмый шул.

● Әдәби Ат

# Ике яр

**Гөлназ ЯППАРОВА**
татар филологиясе бүлеге студенты

Тәрәзләр дә елый бүген,
мин генә түгел.
*Ләйсән Фәтхетдинова*

*Ак кышны сагынып саргайган
табигать
Сиңа яр булырлык, миңа – ят.
Икебез ике яр кешесе без бүген –
Әйләнә дә кайта бу кабат.*

*Ике яр арасын үтәргә алынсак,
Арада – чакрымнар, чакрымнар...
Күңелдә саргайган өметнең шәүләсе
Синдә юк инде ул, миндә бар.*

*Көймәгә утырып, бер ярдан бер ярга
Йөзәргә теләгең юк сыман.
Мин сине шәйләмим дә каршы як ярда,
Су өстен каплаган ак томан.*

*Чакрымнар иш иткән бу салкын тынлыкны
Мин бүген җаныма дус итәм.
Ак кышны сагынып саргайган табигать...
Нәкъ бүген ул сине үз иткән.*



* * *

**Айгөл ЗАКИРОВА**
Массакүләм коммуникацияләр һәм
социология фәннәре институты

*Синнән башка яши алмас кебек идем...
Сизден-бизден, йөрәгемне ут алды...
Җәйләр – яшел,көзләр – сары иде,
Боз-карашың төшкәч,
Төсләр буталды...*

*Бер тамчы су юл ярамы? Ә мин ярдым!
Синең сазлык – минем эзгә бизәлгән.
Агуланган кайнар каным, агуланган
Учын хәнҗәр белән телгән исәрдән...*

*Син көләрсең, иреннәрең җилне үбәр.
Аңламадың сөю йоткан гашыйк хәлен.
Миннән башка үләр дигәнсеңдер,ә мин
Сине күрер өчен бераз
Яшим әле!!!*

* * *

**Ләйсән ФӘТХЕТДИНОВА**
Массакүләм коммуникацияләр һәм
социология фәннәре институты студенты

*Бәрелеп китмәгез үткәндә!
Сөртмәгез яшемне – кипкәндә.
...Көттермә һичкайчан, мин сине
Өзелеп-өзелеп көткәндә.*

*Җанымның тәнемә сыймавы –
Күңелнең килбәтсез биюе.
Йөрәкне учыма кыстым да
Туйганчы йөгердем мин бүген...*

*Колакта уйнаган җырларның
Сүзләрен ишетмә. Ишетмә!
Буй җитеп, яшь белән үссәм дә,
Акылым һаман да бишектә...*

*Бәхетле чакларның вакыты
Сизелми үтә дә китә ул.
Тик күктә очынып йөрүләр
Бер якты һәм кыска күренеш –
Үтә ул...*

*Очасы килгәндә,тилмереп,
Оныту кирәктә күңелгә –
Юату сүзенә түгел лә,
Вак-төяк эшләргә күмеләм...*

*Бәрелеп китмәгез үткәндә!
Башкалар еласа,көлмәгез.
Кайгылы вакытта килмәгәч,
Бәхетле чакта да килмәгез.*

● Шигъри башваткыч

Газетабызда яңа рубрика. Аның авторы Ринат Нуруллин (Нуруллин Риннат Галеевич) - Татарстан Республикасының атказанган уйлап табучысы, техник фәннәр кандидаты. Ул тумышы буенча Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Зур Мөшләк авылыннан. Шигъри башваткычлар «Өч бүре һәм өч сарык» (2004), «Альпинист үрмәкүчләр» (2008) бастырып чыгарылган җыентыкларның дәвамы.

## Кич ич!

*КИЧ җитте ИЧ, көн кучәре
Әйләнә, туктамый һич.
Мичкә утын салган саен:
«Ү-Ү-Ү!»– дип гүли мич.*

*«КИЧ + ИЧ + Ч = ҮҮҮ»,– дип
Ребус төзедем кичә,
Чишелешен тапмадым тик
Бүгенгә кадәр исә.*

*Әллә үҗәтлек җитмәде,
Әллә җитмәде көчем –
Цифрларга күчергәләп
Булмады хәреф күчен.*

*Төнге уникегә кадәр
Ребусның серен аччы,
Җен-пәриләр уянганчы,
Мичтә көл суынганчы!*



Санлы ребусларны чишкәндә шуны исәпкә алырга кирәк: ребустагы аерым бер хәрефкә аерым бер цифр туры килә. Җиңүчегә бүләккә Ринат Нуруллиннан «Альпинист үрмәкүчләр» китабы. Җавапларны электрон почтабызга исемен «Шигъри башваткыч» дип куеп хат языгыз.

● Спорт

# Математиклар спорты

**Илмир ВӘЛИЕВ,**
математика һәм механика институты студенты

Һәр ил, һәр гаилә, гомумән әйткәндә, һәркем үзенә күрә күркәм, матур, кызыклы һәм кабатланмас. Без белем ала торган математика һәм механика институтының да үзенә генә хас традицияләре бар. Шундыйларның берсе, быел беренче мәртәбә үткәрелә торган «Сәламәтлек көне». 28 октябрь көнне «Москва» спорт комплексында үткәрелгән әлеге күңелле чара тәүге тапкыр гына уздырылса да, үз мәйданына бик күп спорт сөюче студентларны җыйды. Бәйрәм институтыбызның социаль һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Петр Великановның, институт укытучылары, активистларының тәбрикләү сүзләре белән башланып китте.

Институтыбызның беренчедән алып дүртенче курс студентларына кадәр һәм укытучылар командалары волейбол, баскетбол, теннис, күңелле стартлар кебек спорт төрләрендә көч сынашты. Һәр команда да үзенең бердәм, көчле, иң-иң икәнлекләрен дәлилләде. Чыннан да, беркемнең бирешәсе килмәде, соңгы көчләрен куеп булса да, һәр команда беренче булырга тырышты. Ниһаять, пьедестал баскычлары үз ияләрен тапты. Көчле көрәштән соң, һәр спорт төрендә җиңүчеләр билгеләнде. Бер команда да сынатмады. Ни дисәң дә, университетыбызда иң-иңнәр генә белем ала. Җиңгән командаларга да диплом һәм татлы призлар тапшырылды. Шундый күңелле һәм мавыктыргыч чара оештырганнары өчен, университет һәм институт җитәкчелегенә, ярдәм иткән һәркемгә зур рәхмәтебезне белдерәбез.

Әйе, яңа гына башланып киткән традицияләрнең беренчесе төерсез булды. Алдагы елларда да бу чара әһәмиятен югалтмас, һәркайсының йөрәгендә онытылмас студент елларының бер чаткысы, якты бер мизгеле булып калыр дигән теләктә калам.



● Сәламәтлек

# Йокыңны туйдыр!

**Динара ЗИННӘТОВА,**
хәбәрче

Һәр студент йокы кадерен белә. Шулай да күпләр вакытында йокларга ятмыйча, кичләрен социаль челтәрләрдә утырырга ярата. Гадәттә, моның нәтиҗәсе: икенче көнне университетта үзеңне кинолардагы зомби итеп хис итү һәм «бүген иртәрәк ятачакмын» дигән вәгъдә бирү. Тик кичен алдагы хәл кабатлана һәм студентлар арасында еш таралган бик җитди проблема – йокы туймау барлыкка килә.



Атна азагында студент, ял көннәрендә туйганчы йоклармын әле, дип өметләнә башлый. Ләкин күп очракларда мескенкәйгә ялларда да «кешечә» йокларга бирмиләр! Туган йортына кайтучыларны вокзалдагы иртәнге автобус ашыктыра, йә булмаса, тыныч кына йоклап яткан арада, иртә таңнан берәр күршең дрель белән бораулый башлый. Шуннан соң агрессия барлыкка килә, ә бу – йокы туймауның соңгы стадиясе. Исеңдә тот: йокы туймау сәламәтлегеңә бәйле күп кенә җитди проблемаларга китерергә мөмкин.

Йокыны ничек туйдырырга соң?

Гадәттә, каты итеп йокы килгәндә, лекция һәм урамдагы һава торышы синең өчен мөһим булмый. Ә бу нәрсәләр, һичшиксез, сиңа кызык тоелырга тиеш. Син бит бүлмәдә үсә торган гөл түгел, ә тере кеше! Компьютер һәм виртуаль дусларың тормышыңның аерылмас бер өлеше булса да, реаль дөнья һәм реаль дусларың йөз мәртәбә яхшырак.

Үзеңне интернетка керү җайланмаларыннан, вакытлыча булса да, азат итеп тор. Бу сиңа глобаль челтәргә бәйлелегеңне җиңәргә ярдәм итәчәк. Дөньяда интернеттан башка да кызык нәрсәләр тулып ята бит. Укудан соң, тулай торак бүлмәсендә генә утырма. Дусларың белән очрашып, күңел ач, әйтик, паркта йөрегез, киногa барып кайтыгыз.

Табиблар кичке ун-унбергә кадәр ятарга киңәш итә. Бу вакытта организм ял итә, нерв системасы тынычланган, йоклап китәргә җиңел булачак. Урта яшьтәге кешегә кирәкле энергия җыю өчен, 7-8 сәгать йокы җитә. Моның өчен иң файдалы вакыт: кичке унбердән - иртәнге бишкә кадәр. Һәрхәлдә, йокы вакыты төнге икедән иртәнге дүрткә кадәрге аралыкны үз эченә алырга тиеш. Көндез йокламаска тырыш, аеруча кояш баеганда йоклау зарарлы. Йокы дәвамлылыгы көн буена ашалган ризык күләменә дә бәйле: никадәр аз ашасаң, организмыңа шулкадәр азрак йокы да кирәк.

Тагын бер мөһим нәрсә: иртән, хәтта син бик иртә уянсаң да, урында озак ятарга тырышма. Күзеңне ачкач та, елмай, юрганыңны читкә алып куй һәм тор! Салкын су белән битеңне юу сиңа өстәмә көч бирәчәк. Иртә торуның уңай якларын санап бетергесез: иртәнге гимнастика һәм төрле көндәлек эшләр өчен вакыт табылыр.

Йокларга вакытында ят һәм үзеңне күпкә яхшырак хис итә башларсың. Кәефең күтәренке булганда, син башкаларга да шатлык һәм позитив энергия генә бирерсең, алар дә сиңа тартылыр. Дөнья белән дус булырга теләсәң, йокы белән дус бул, студент!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рифат Гали улы Сәлахов
Иҗат коллективы: Д.Р.Әхмәтова, А.Ю.Садыйкова, Д.Р.Зиннәтова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.